КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 октябрь г.Казань № 902

Буа муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге башкарма комитетының Буа муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 0,6248 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:14:120104:52 кадастр саны белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин